ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19 03 2016 г. № 18

Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче затның үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 281.1 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 мартындагы 208 номерлы «Федераль дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук федераль дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү кагыйдәләрен раслау хакында» карарына таянып, Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты карар бирә:

1. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруның тәртибен кушымтада бирелгән тәртиптә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Г. Шакиров

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА»
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881

Кушымта
Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты карары белән расланды
2026 елның 19 гыйнвар № 18

Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру
ТӘРТИБЕ

1. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат эшкә кергәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртип буенча тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында) каралган белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.

2. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында каралган белешмәләр эш бирүченең вәкаләтле структур бүлекчәсенә - Түбән Кама муниципаль районы Советының кадрлар сәясәте һәм персонал белән идарә итү бүлегенә тапшырыла.

3. Әлеге Тәртип нигезендә муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керә торган зат тарафыннан тапшырыла торган белешмәләр конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

4. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керүче зат үзе тапшырган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең чагылдырылмавын яисә хаталар булуын ачыклаган очракта, ул белешмәләр тапшырылган көннән алып бер ай эчендә әлеге Тәртипнең 1 пункты нигезендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

5. Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең коррупциягә каршы тору турындагы законнарны үтәвен һәм тиешле карарлар кабул итүен тәэмин итү, шул исәптән объектив сәбәпләр аркасында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмау максатларында комиссия төзелә.

6. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән зат объектив сәбәпләр аркасында үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмаган очракта, ул Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә тиешле гариза белән мөрәҗәгать итә.

Әлеге Тәртипнең 5 пунктын үтәү өчен төзелгән комиссия әлеге гаризаны карый һәм нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән затка карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмау сәбәбе объектив һәм җитди дип танырга;

б) үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тапшырмау сәбәбе нигезле түгел дип танырга.

Бу очракта комиссия әлеге затка күрсәтелгән белешмәләрне тәкъдим итү чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмау сәбәбе объектив түгел һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан читләшү ысулы булып тора дип танырга. Бу очракта комиссия эш бирүчегә гражданинны эшкә алудан баш тартуны тәкъдим итә.